РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

09 ноябрь 2023 ел №211

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче зат хокукларыннан азат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» 2017 елның 13 декабрендәге №130 карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июльдәге № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм оешмаларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче зат хокукларыннан азат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» 2017 елның 13 декабрендәге № 130 карарына (Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 13 декабрендәге №199, 2019 елның 14 ноябрендәге №252, 2019 елның 13 декабрендәге №260, 2020 елның 13 мартындагы № 272, 2020 елның 29 декабрендәге

№10 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче зат хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген түбәндәге объектлар белән тулыландырырга:

| № п/п | Милек атамасы | Милекнең урнашу урыны | Мәйдан (кв.м.) |
|---|---|---|---|
| 1 | Бина | Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авылы, Беренче Май урамы, 27 йорт, 10 нчы бина | 15,5 |
| 2 | Бина | Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авылы, М. Титов урамы, 22А йорты, 15 нче бина | 23,8 |

1.2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче зат хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлегеннән күчемсез милек объектын төшереп калдырырга:

| № п/п | Милек атамасы | Милекнең урнашу урыны | Мәйдан (кв.м.) |
|---|---|---|---|
| 1 | Бина | Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Иске Кади авыл җирлеге, Иске Кади авылы, Совет урамы, 6 йорт. | 131,54 |

2. Әлеге карарны «Безнен Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов